ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2022 Олы Кайбыч ав. 555

Халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә
тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының «2022 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең иң чик (максималь) индекслары турында» 2021 елның 15 декабрендәге ПУ-958 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 01 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре тарифлары кушымта нигезендә билгеләнә һәм гамәлгә керә.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты 2022 елның 26 гыйнварындагы 19 номерлы «2022 елда халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Э.Х.Заһидуллина

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022е. «22» 12
555 номерлы карарына
кушымта

**2022 елның 01 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре тарифлары**

| № п/п | Түләү атамасы | Хезмәт үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлегенә тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2022 елның 1 декабреннән 2022 елның 31 декабренә кадәр | 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,89 | 0,89 |
| 2 | Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 3,73 | 3,73 |
| 3 | Йорт эчендәге су үткәргеч-канализация челтәрләренә агымдагы ремонт һәм карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,40 | 2,40 |
| 4 | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,30 | 1,30 |
| 5 | Наем буенча база ставкасы | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 5,00 | 5,00 |
| 6 | Тышкы фасад эчендәге газүткәргечләргә техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,59 | 0,59 |
| 7 | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,26 | 1,26 |
| 8 | Җилләтү каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,51 | 2,51 |